# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

2023 елда Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Уразай авыл җирлеге Уразай торак пунктында гражданнардан үзара салым кертү турында

**8 ноябрь 2022 ел** **№2**

2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьясы, 2004 елныц 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Уразай авыл җирлеге Уразай торак пунктында гражданнар җыены

**КАРАР ИТТЕ:**

1.2023 елда 1 төркем инвалидлар, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлар, махсус хәрби операциягә мобилизациялэнгэннэрнен гаилэ эгъзаларыннан тыш, түләүне бер тапкыр киметеп 2 төркем инвалидлар, 80 яшьтән өлкәнрәк пенсионерлар, күп балалы гаиләләр өчен 150 сум күләмендә, Азнакай муниципаль районы Уразай авыл җирлеге Уразай торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 300 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә буенча түбәндәге эшләрне башкаруга җибәрергә:
- 1941-45 елларда Бөек Ватан сугышында һәлак булган сугышчыларга багышланган һәйкәлне ремонтлау;
- авыл җирлеге юлларын кардан чистарту;
- авыл җирлеге территорияләрен чистарту( чүп үләне чабу, агачларны кисү һәм чүп җыю);
- халык өчен мәдәни чаралар үткәрү (Җиңү көне -9 Май, Сабантуй, өлкәннәр көне, Инвалидлар көне, Яңа ел бэйрэмнэре);
-Беларус 82 тракторына запас частьләр, ягулык-майлау материаллары сатып алу, тракторчыга хезмәт хакы түләү керә.

3. Әлеге карарны, кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә, Уразай авыл җирлеге мәгълүмати стендларында һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында (http://aznakaevo.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Азнакай муниципаль районы ____________ А.М.Шэрифуллина
Уразай авыл җирлеге башлыгы (имза) (имза расшифровкасы)